| | |
|---|---|
| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2025 г.Лениногорск № 69

**2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Лениногорск муниципаль районы бюджеты проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 17 статьясы, Лениногорск муниципаль районы халкының Лениногорск муниципаль районы бюджеты проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2017 елның 30 маендагы 35 номерлы карары белән расланган яңа редакциядәге Лениногорск муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (15.12.2022 ел, №70 үзгәрешләр белән)т уры китереп КАРАР БИРӘМ:

1. 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Лениногорск муниципаль районы бюджеты проекты (алга таба – бюджет проекты) буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

2. Инициатором проведения публичных слушаний по проекту бюджета является Исполнительный комитет муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» Республики Татарстан.

3. Билгеләргә:

гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты-2025 елның 9 декабре 15.00 сәгатьтә;

гавами тыңлаулар уздыру урыны – Лениногорск шәһәре, Кутузов ур., 1 йорт, Лениногорск шәһәре мэриясенең утырышлар залы;

бюджет проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы

күрсәтелгән адрес – Лениногорск шәһәре, Садриев урамы, 15нче йорт, 16нчы кабинет эш көннәрендә 8-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр;

бюджет проекты буенча гаризалар кабул итү сроклары-2025 елның 5 декабренә кадәр;

бюджет проектын халыкны таныштыру өчен Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) һәм Лениногорск шәһәре, Кутузов ур., 1нче йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштырырга .

4. Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитетына:

бюджет проекты буенча билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар оештырырга һәм уздырырга;

гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар тәкъдимнәрен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук эшләп бетерелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) бюджет проектын тапшырырга;

2025 елның 12 декабренә кадәр бюджет проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) урнаштырырга .

5. Бюджет проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәрне 2025 елның 21 ноябреннән дә соңга калмыйча «Лениногорские вести» газетасында урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

М.Н.Гирфанов

Сытдикова Д.Р.
5-04-00